**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, ТР Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
422700, Высокогорский район РТ,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**20 февраль 2015 ел** **№ 174**

Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Красносельский
авыл җирлеге Башкарма комитеты
вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан
Республикасы Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетына тапшыру
турында килешүне раслау хакында.

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 нче елның 23 нче июнендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 нче статьясындагы 4 нче өлешенә таянып, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 нче елның 25 нче октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән, һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы белән, Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән килешү проектын, Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына җирләр белән эш итү буенча вәкаләтләр тапшыру турында килешү проектын, аларга дәүләт милке чикләнмәгән һәм җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре расланган җирлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү буенча килешү проектын 2012 нче елның 12 няе декабрендә Красносельский авыл җирлеге Советы карарында расларга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә кушымта нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Зайнуллин Р.А. ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районының
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин

2015 нче елның __________№ ___
Красносельский авыл җирлеге Советы
карарга кушымта

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына Красносельский авыл җирлеге территориясендә урнашкан һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләрен җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең раслануы булганда тапшыру турында КИЛЕШҮ.**

Биектау т.ю. ст. поселогы «___» нче февраль 2015 нче ел

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты, Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Зайнуллин Раил Әюп улы аша, Красносельский авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә эш итүче, алга таба авыл җирлеге Башкарма комитеты дип аталучы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты, бер яктан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмә нигезендә эш итүче Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Мөхлисов Илнар Ильяс улы аша, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 нче статьясындагы 4 нче өлешенә таянып, әлеге Килешүне түбәндәгечә төзеделәр:

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешү Башкарма комитетка җирлек Башкарма комитетының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешен тапшыруны беркетә.

1.2. Җирлекнең Башкарма комитеты дәүләт милке чикләнмәгән һәм Красноселҗский авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен үтәүне районның Башкарма комитетына тапшыра.

2. Субвенцияләрнең еллык күләмен билгеләү тәртибе

2.1. Әлеге Килешүне предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру ел саен Красносельский авыл җирлеге бюджетыннан Биектау муниципаль районы бюджетына бирелә торган субвенцияләр хисабына гамәлгә ашырыла.

2.2. Яклар ел саен тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле субвенцияләр күләмен билгели.

2.3. Әлеге Килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Красноселҗский авыл җирлеге бюджетыннан Биектау муниципаль районы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Якларның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Районның Башкарма комитеты әлеге Килешүнең 1 нче бүлеге һәм гамәлдәге законнар нигезендә аңа җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.2. Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закон һәм норматив хокукый актларында каралган срокларда һәм күләмнәрдә мәгълүмат алмашырга тиеш.

3.3. Җирлекнең Башкарма комитеты район Башкарма комитетына тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалануны тикшереп тора ала.

4. Килешүнең гамәлдә булу вакыты, аны туктату вакыты һәм тәртибе

4.1. Әлеге Килешү Красносельский авыл җирлеге советы һәм Биектау муниципаль районы Советы раслаган вакыттан үз көченә керә.

Килешү 2018 нче елның 1 нче мартына кадәр гамәлдә.

4.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

4.2.1. Яклар килешүе буенча.

Бер яклы тәртиптә:

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкин булмаса, шул исәптән Россия Федерациясе законнарын һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарын үзгәрткән очракта;

- җирлек Башкарма комитеты инициативасы буенча, икенче Якка 1 ай эчендә хәбәр ителгән очракта, район Башкарма комитеты тарафыннан үзенә тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә гамәлгә ашырмау (яки тормышка ашмау) факты билгеләнгән очракта, субвенцияне максатчан файдаланмау.

4.3. Килешүне өзү язма рәвештә рәсмиләштерелә.

4.4. Әгәр Яклар әлеге Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән вакыт узгач, утыз көн эчендә Килешүне өзәргә ниятләүләре турында белдермәсәләр, ул Килешүне яңа шундый ук срокка үзгәртеп төзелгән дип санала.

5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар әлеге Килешүдә каралган вазыйфаларны гамәлдәге законнар нигезендә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

5.2. Район Башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә гамәлгә ашырмау фактын билгеләү әлеге килешүне берьяклы өзү өчен нигез булып тора. Килешүне өзү санап үтелгән субвенцияләрне документлар белән расланган факттагы чыгымнарны кире кайтаруга китерә, Килешүне өзү яисә өзү турында язма хәбәрнамә язу алган вакыттан соң 30 көн эчендә.

5.3. Районның Башкарма комитеты үзенә тапшырылган вәкаләтләрне финанс чаралары белән тәэмин ителгән дәрәҗәдә гамәлгә ашырган өчен җаваплы була.

5.4. Әлеге Килешүдә каралмаган Якларның җаваплылыгы чаралары Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган граждан законнары нормалары нигезендә кулланыла.

6. Башка мәсьәләләр

6.1. Якларның үзара ризалыгы яисә гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә әлеге Килешүгә язма рәвештә үзгәрешләр һәм (яисә) өстәмәләр кертелергә мөмкин, алар Яклар тарафыннан имзаланган вакыттан алып әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

6.2. Әлеге Килешүне үтәгәндә барлыкка килгән бәхәсләр һәм каршылыклар әлеге Законнарда каралган тәртиптә каралырга тиеш.

6.3. Әлеге Килешү тигез юридик көчкә ия Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхә буенча 2 (ике) нөсхәдә төзелгән.

7. Якларның реквизитлары һәм имзалары:

| | |
|---|---|
| 422700, ТР, Биектау районы,<br>Биектау т.ю. ст. пос,<br>Совет урамы, 13 нче йорт | 422700, ТР, Биектау районы,<br>Биектау т.ю. ст. пос.,<br>Кооперативная урамы, 5 нче йорт. |

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе

______________ Р.А. Зайнуллин
М.п.

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

____________ И.И. Мухлисов
М.п.